| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2019 Казан шәһәре № 10-74/кс

2020 елга «Яңа Чишмә ТКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Яңа Чишмә ТКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен, шушы карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүлеп, эчә торган суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабрендә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Яңа Чишмә ТКХ» муниципаль унитар предприятиесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-74/кс карарына кушымта

2020 елга салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу белән шөгыльләнүче «Яңа Чишмә ТКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга һәм су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Яңа Чишмә ТКХ» МУП* | | | | |
| 1.1 | Яңа Чишмә, Петропавловск, Әҗи, Кызыл Октябрь, Өтәшкә, Черемухово, Тубылгытау, Чебоксар авыл җирлекләре кулланучылары өчен | 25,12 | 25,62 | | |
| 1.2 | Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы, Екатериновка авыл җирлегенең Яңа Иванай авылы, Архангел, Акбүре, Буревестник авыл җирлекләре кулланучылары өчен | 24,92 | 25,44 | | |
| 1.3 | Яңа Чишмә авыл җирлеге кулланучылары өчен | | | 30,40 | 30,89 |
| 1.4 | Шахмай авыл җирлеге кулланучылары өчен | 20,66 | 20,73 | | |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге